ГЛАВА БАЛТАСИНСКОГО ГОРОДСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ БАЛТАСИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БАЛТАЧ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАЛТАЧ ШӘҺӘР ЖИРЛЕГЕ БАШЛЫГЫ

---

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ**

**КАРАР**

«06» октябрь 2025ел

№ 3

**Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районының "Сосновка авыл җирлеге" һәм "Норма авыл җирлеге" муниципаль берәмлекләре белән чиктәш җирдә «Балтач шәһәр тибындагы поселогы " муниципаль берәмлеге чикләрен үзгәртү мәсьәләсе буенча гавами тыңлаулар билгеләү турында**

«Гавами хакимиятнең бердәм системасында җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2025 елның 20 мартындагы 33-ФЗ номерлы Федераль закон, Татарстан Республикасы Балтач район Советының «Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы муниципаль берәмлекләре чикләрен үзгәртү турында»2025 елның 11 сентябрендәге 343 номерлы карары нигезендә, Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Балтач шәһәр җирлеге Советының 03.06.2020 № 146 карары белән «Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Балтач шәһәр җирлегендә гавами тыңлаулар (җәмәгать фикер алышулары) үткәрү тәртибе турында нигезләмәне раслау хакында " (редакциядә 28.06.2022 № 59, 30.10.2023 № 93 үзгәрешләр белән), гражданнарның Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районының «Балтач шәһәр тибындагы поселогы» муниципаль берәмлеге чикләрен гавами тыңлаулар уздыру юлы белән үзгәртү турындагы мәсьәлә буенча фикер алышуда катнашу хокукларын үтәү максатларында Карар бирәм:

1. Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районының «Балтач шәһәр тибындагы поселогы» муниципаль берәмлеге белән чиктәш җирдә «Балтач шәһәр тибындагы поселогы» муниципаль берәмлеге чикләрен үзгәртү мәсьәләсе буенча кушымта нигезендә 2025 елның 25 октябренә 14.00 сәгатькә Балтач шәһәр җирлеге бинасында түбәндәге адрес буенча гавами тыңлаулар үткәрүне билгеләргә: Татарстан Республикасы, Балтач муниципаль районы, Ленин урамы, 45 йорт (2 кат).

2. Гавами тыңлауларда карала торган мәсьәләләр буенча тәкъдимнәр һәм искәрмәләр 2025 елның 24 октябренә кадәр түбәндәге адрес буенча кабул ителә: Татарстан Республикасы, Балтач муниципаль районы, Ленин урамы, 45 йорт (Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Балтач шәһәр җирлеге Башкарма комитетының административ бинасы). Консультацияләр өчен Телефон: 8 (843)68-2-52-15.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматын рәсми порталында бастырып чыгару юлы белән халыкка җиткерергә (https://pravo.tatarstan.ru), Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районының рәсми сайтында (https://baltasi.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Балтач шәһәр җирлегенең мәгълүмат стендларында:

- Балтач ш.тп, Ленин ур., 45 йорт.;
- Балтач штп, Ленин ур., 52 йорт.;
- Көек авылы, Ибраһимов ур., 20а;
- Курмала ав., Совет ур., 41а йорт.;

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үземдә калдырам.

Балтач шәһәр җирлеге башлыгы Р.Р.Нотфуллин